ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 03.10.2025 1596 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 17 октябрендәге 1642 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 февралендәге 166 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларга, махсус хәрби операциядә катнашкан затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына торак урыннары бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 21 августындагы 621 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 17 октябрендәге 1642 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1.2. пунктын түбәндәге эчтәлекле 4 пунктчасы белән тулыландырырга:

«4) махсус хәрби операциядә катнашучы, социаль ипотека системасында исәпкә кую максаты белән гариза бирүче Россия Федерациясе гражданы, махсус хәрби операциядә катнашу чорында аның гаиләсе әгъзалары һәлак булган очракта, әгәр дә элек аларга әлеге категория буенча торак шартларын яхшырту хокукы гамәлгә ашырылмаган булса»;

1.2. Регламентның 2.6.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле 17 пунктчасы белән тулыландырырга:

«17) мөрәҗәгать итүче - махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен - махсус хәрби операциядә катнашу турындагы документ, ә махсус хәрби операциядә катнашу чорында һәлак булган очракта, аның гаилә әгъзалары, әгәр элек аларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 августындагы 621 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булган затларга торак урыннары бирү Тәртибе нигезендә торак шартларын яхшыртуга хокук гамәлгә ашырылмаган булса.

17.1) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре хәрби комиссариаты тарафыннан гражданның махсус хәрби операциядә катнашуынраслаучы белешмә;

17.2) махсус хәрби операциядә һәлак булучының (вафат булучының) үлеме турында таныклык күчермәсе;

17.3) махсус хәрби операциядә катнашу яки аны үткәрүгә бәйле бурычларны турыдан-туры үтәү нәтиҗәсендә махсус хәрби операциядә катнашучының һәлак булуын (вафат булуын) раслый торган документларның күчермәсе;

17.4) һәлак булучының (вафат булучының) үлеменә китергән гариплек (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яисә авыруның сәбәп бәйләнеше турында махсус хәрби операциядә катнашу яисә аны үткәрүгә бәйле бурычларны турыдан-туры үтәү турында хәрби-табиб комиссиясе бәяләмәсе күчермәсе»;

1.3. Регламентның 2.8.2.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле 9 пунктчасы белән тулыландырырга:

«9) әлеге Регламентның 2.6.1 пунктындагы 17 пунктчасында билгеләнгән «мөрәҗәгать итүче» төшенчәсенә туры килмәү».

1.4. Регламентның 2.8.2.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле 10 пунктчасы белән тулыландырырга:

«10) махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен социаль ипотека программасында кабат катнашу (мөрәҗәгать итүче 1.2. пунктының 4 пунктчасында күрсәтелгән зат булса)»;

1.5. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 5 нче кушымтасын яңа формада расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 21 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3 Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.А. Томилин

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5D5B832C0D4CC8A96C405A04F5061337
Владелец: Томилин Андрей Александрович
Действителен с 25.09.2024 до 19.12.2025

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

____________________________________
**җирле үзидарә органы җитәкчесенә**
____________________________________
**(район, шәһәр исеме)**
___________________________________
**гражданин __________________________,**
**(фамилиясе, исеме, атасының исеме**
**(соңгысы - булган очракта) тулысынча**
____________________________________
**(түбәндәге адрес буенча шәһәрдә, поселокта, авылда яшәүче)**
______________________________________________
**(почта индексы, тулы адресы, элемтә өчен телефоны)**

______________________________________________
______________________________________________
**__________ елның «___» ________________________**
**(көне, ае, елы)**

**ГАРИЗА**

**_____________________________________________________белән бәйле рәвештә**
**(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкның сәбәпләрен күрсәтергә,**
______________________________________________________________________________
**(гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган торак мәйданы белән тәэмин ителеш социаль ипотека буенча исәпкә алу нормасыннан түбәнрәк түбәндәгеләрне исәпкә алу ____________________________________________________**
**санитар һәм техник таләпләргә туры килми торган торак бинада яшәү, һәм**
______________________________________________________________________________
**коммуналь фатирда яшәү, биләгән торак урыннарын сүтү кирәклеге)**
______________________________________________________________________________
**(биләп торучы торак хокуклары объектының тибын күрсәтергә: аерымланган (коммуналь), бүлмәләр саны)**
____________________________________________________________________________,

**сездән мине гаиләгез белән ____ составта яшь гаиләләрнең социаль ипотекасы/бюджет/авыл ипотекасы буенча торак шартларын яхшырту өчен учетка алуыгызны сорыйм (кирәклесенең астына сызарга кирәк).**

Билгеләнгән рәвештә, гаиләмне социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрне үз эченә алган гариза кушымтасы кушымта итеп бирелә.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүгә, исәпкә алу турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен кирәкле документларны алар тарафыннан, шулай ук махсуслаштырылган оешма тарафыннан соратуга ризалык бирәбез.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары безне исәпкә алган очракта, гаризада күрсәтелгән белешмәләр үзгәргәндә, алар турында җирле үзидарә органнарына исәпкә алу урыны буенча язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш булачакбыз, дип кисәттеләр.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары гаризада күрсәтелгән белешмәләр ачыкланмаган очракта, без законда билгеләнгән тәртиптә исәптән төшереләчәкбез.

Минем керемнәрем һәм мөлкәт хокукында булган белешмәләрне күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәве буенча тиешле салым органнарында һәм органнарында тикшерүгә ризалык бирәм.

Гаризаны карау нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйбыз:

☐

**дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Бердәм порталының шәхси кабинетында электрон рәвештә;**

☐ **электрон рәвештә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинетта;**

☐ **күпфункцияле үзәктә.**

**Мөрәҗәгать итүче ____________________________________**

**(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - тулысынча булганда), имзасы)**

**Эшкә сәләтле**

**Гаиләнең эшкә сәләтле әгъзалары: 1.________________________________**

**2.______________________________________**

**3.__________________________________________**

**4.__________________________________________**

**(гаиләнең хокукка сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)**

**"__" ________ 20__ ел**

**(датасы, хәрефләр белән күрсәтеп)**

# ГАРИЗА БИРҮЧЕНЕҢ АНКЕТАСЫ

1. Гариза бирүченең <*> фамилиясе, исеме, атасының исем__________________
(тулысынча)
______________________________________________________________________

2. ___________________________________________________ адресы буенча яшим
(район, урам, йорт, фатир, бүлмә)
______________________________________________________________________
(элемтә өчен телефонны күрсәтергә: өй телефоны, эш телефоны)

3. Шәхесне раслый торган документ;
(документ төре)
сериясе _______ номеры ____________________ кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән _________________________________________________________________

4. Туган көне ____________________________________________________________
(көне, ае, елы)

5. Туу урыны _____________________________________________________________
______________________________________________________________________

6. Салым түләүченең түләүченең тәңгәлләштерү номеры ______________________
(Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры – барлык унике санны да күрсәтергә)

7. Эш урыны _____________________________________________________________
(оешманың, бүлекнең тулы исемен, вазифасын күрсәтергә)
______________________________________________________________________
(әгәр гариза бирүче эшләми икән, эшләмәүнең сәбәбен күрсәтергә)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

8 Салым түләүче оешманың тәңгәлләштерү номеры __________________________________
(әгәр гариза бирүче эшләми икән, ИНН урынына нульләр куела, ягъни эшләмәүче өчен ИНН - 0 000 000 000)

9. Соңгы эш урынында стаж ____________________ |__|__|
(еллар санын күрсәтергә)

10. Гомуми эш стажы ______________________________ |__|__|
(еллар санын күрсәтергә)

11. Бюджет өлкәсендә эш стажы ____________________ |__|__|
(еллар санын күрсәтергә)

12. Гаилә ______ кешедән тора:


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча <*> | Туганлык мөнәсәбәтләре <**> | Туган көне | Туу урыны | Шәхес таныклыгы | | | | | Физик затның ИНН (салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры) | СНИЛС (аерым шәхси счетның иминият номеры) | Эш, уку урыны | Эш стажы | Оешманың ИНН (салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | документ төре | сериясе | номеры | кем тарафыннан бирелгән | бирелү вакыты | | | | | |
| 1 | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | | | | | | |

13. Мин һәм минем гаилә әгъзалары түбәндәге торак мәйданны биләп торабыз:

| т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Туганлык мөнәсәбәтләре | Туган көне | Адресы | Теркәлү вакыты | Милек төре (фатир, бүлмә, торак йорт), мәйдан, кв. метр (гомуми/торак) | Куллану нигезләре (социаль наем, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүе яки милек хокукы нигезендә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | |

Моннан тыш, мин һәм минем гаилә әгъзалары белән бергә түбәндәге затлар яшиләр:

| т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Туганлык мөнәсәбәтләре | Туган көне | Шәхес таныклыгы (серия, номер, кем тарафыннан бирелгән) | Аерым шәхси счетның иминият номеры | Адресы | Теркәлү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

14. Милек хокукында миңа һәм минем гаилә әгъзаларына караган торак урыннарның барлыгы турындагы белешмәләр:

| т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> (тулысынча) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Адресы | Милек төре (фатир, бүлмә, торак йорт), мәйданы, кв. метр | Милек турындагы таныклык буенча теркәү датасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2.. | | | | | |

15. Соңгы өч елда гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының торак шартларын начарайтуга яки үзгәртүгә китергән торак урыннар белән гражданлык-хокукый килешүләре <****>:

| т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> (тулысынча) | Соңгы 5 елда яшәү адресы | Мәйданы (гомуми/торак) | Гаилә составы (кеше саны) | Теркәлү датасы (өземтәләр) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |

16. Гаиләдәге бер әгъзаның гомуми мәйдан белән тәэмин ителешенең җыел

(Гаиләдәге 1 әгъзага ничә кв. метр туры килүен күрсәтергә)

17. Биләп торган торак урынның төре
________________________________________________________________
(торак урынның төрен күрсәтергә шәхси торак йорт,
________________________________________________________________
блоклап төзелгән йорт, коммуналь фатир, фатир, бүлмәләр саны)

________________________________________
(төзекләндерү стандартын күрсәтергә)
________________________________________________________________

18. Банкларның һәм башка оешмаларның кредит акчаларын
теләсә нинди түләүләргә куллану (фатир, техника сатып алу, уку өчен түләү һ.б.) (әйе 1, юк - 2) ☐

19. Айлык түләүләр суммасы ____________________________________
(конкрет түләү суммасын күрсәтергә)

20. Түләү вакытының тәмамлануы
________________________________________________________________

21. Тутырылган декларация нигезендә гаиләдә 1 кешегә туры килә торган айлык җыелма керем түбәндәгене тәшкил итә: __________________________________

22. Беренчел кертем ясау (пай туплау) мөмкинлеге __________________
(мөмкинлек булса,
ничә процент икәнен күрсәтергә: 10 %, 20 %, 30 %тан артык)
________________________________________________________________

23. Ташламалар категориясе ___________________________
(бар/юк (астына сызарга)
________________________________________
(ташлама нинди нигездә бирелгән, төрен күрсәтергә:
________________________________________________________________
авария хәлендәге торак фондыннан күчерү программасында катнашучы затлар;
________________________________________________________________
Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына,
авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнар
________________________________________________________________
«Маяк» берләшмәсендәге, һәм аларга тиңләштерелгән затлар; биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр,
________________________________________________________________

торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ затлар; Бөек Ватан сугышында катнашучылар; башкалар)

24. Гражданнарның мәшгульлеге өлкәсе буенча квоталар категориясе: (гариза бирүченең кайсы категориягә каравын күрсәтергә):

.

☐ бюджет өлкәсе хезмәткәре

☐ оешма хезмәткәре

☐ яшь гаилә

☐ авыл торак пункты хезмәткәре

☐ ашыгыч ярдәмгә мохтаҗ

☐ катнашучылар/гаиләләрдә махсус хәрби операциядә катнашучылар

25. Таләп ителә торган (алырга тели торган) торак төре: ____________________________________________________________________________

Әлеге анкетадагы мәгълүматларның түбәндә күрсәтелгән көнгә дөрес һәм төгәл булуын раслыйм.

Мөрәҗәгать итүче: ________________________________________

(тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)

Эшкә сәләтле

Гаиләнең эшкә сәләтле әгъзалары: 1.________________________________

(гаиләнең хокукка сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

2.______________________________________

3.__________________________________________

4.__________________________________________

5.______________________________________

6.____________________________________

"__" ________ 20__ ел

(датасы, хәрефләр белән күрсәтеп)

--------------------------------

<*> Атасы булган очракта күрсәтелә.

<**> Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләре һәм тәртибенең 6 номерлы кушымтасының 2.6. пунктында күрсәтелгән кодлар буенча.

<***> Эш стажы түбәндәгечә күрсәтелә, мәсәлән: 20/01/14, монда 20 – гомуми эш стажы, 01 – соңгы эш урынындагы эш стажы, 14 – бюджет өлкәсендәге гомуми эш стажы;

балаларның эш стажы түбәндәгечә күрсәтелә: 00/00/00

<****> Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең, кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ оешмаларның һәм гражданнарның квоталар категориясенә керүче гражданнарны тотыруга мәҗбүри.

Лист согласования к документу № 1596 от 03.10.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 03.10.2025 14:47

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Томилин А.А. | | Подписано 03.10.2025 - 15:41 | - |